Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле авылында гражданнар җыены

КАРАР

21.11.2025 № 2

2026 елда Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы Бөрешле
авыл җирлегенең Бөрешле авылында
гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү турында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында "2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге башлыгының 2025 елның 11 ноябрендәге 4 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авылы гражданнар җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2026 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, балигъ булмаган балалары булган күпбалалы гаиләләрдән, 18 яшькә кадәрге балаларны тәрбияләүче ялгыз аналардан, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы көчләренә сроклы хезмәткә чакырылганнардан, 80 яшькә җиткән һәм өлкәнрәк затлардан тыш, кертергә.

Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Бөрешле авылында вак таш белән капланган юлларда чокырларны ремонтлау; Бөрешле авылында юлларны кардан чистарту);

2) тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Бөрешле авылында урам яктыртуына техник хезмәт күрсәтү);

3) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Бөрешле авылында территорияне чабу).

Узган еллардан калган үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Бөрешле авылында территорияне чабу).

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында

http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru “Бөрешле авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Бөрешле авыл җирлеге башлыгы Л.А. Смирнова